КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1181

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм аларның торышын мониторинглау дәүләт программасын формалаштыруның һәм үтәлешен мониторинглауның дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2015 ел, 24 февраль, 107 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм аларның торышын мониторинглау дәүләт программасын формалаштыруның һәм үтәлешен мониторинглауның дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2015 ел, 24 февраль, 107 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 май, 370 нче; 2020 ел, 30 май, 441 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «Торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм аларның торышын мониторинглау дәүләт программасын» сүзләрен «Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау һәм торак фонды объектлары торышын мониторинглау буенча төбәк программасын» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм аларның торышын мониторинглау дәүләт программасын» сүзләрен «күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау һәм торак фонды объектлары торышын мониторинглау буенча төбәк программасын» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Системаның функциональ операторы һәм мәгълүматлар базасы операторы, шулай ук Системаны мәгълүмат белән тулыландыруны һәм аннан файдалануны координацияләүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле республика башкарма хакимият органы итеп – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы.»;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Системаның техник операторы Системаны үстерү һәм техник тәэмин итеп тору чараларын үткәрүне тәэмин итү өчен «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт заказчысы тарафыннан билгеләнә дип билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин